**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУТЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Клубная, д.1а, село Кутема, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Клуб урамы, 1а йорты, Күтәмә авылы, 423112

тел.+7(84396) 4-30-88, email: Kut.Cmn2@tatar.ru

---

№ 1 30 гыйнвар 2023 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Күтәмә авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль үткәргәндә тикшерү кәгазе формасын (контроль мәсьәләләр исемлеген) раслау турында» 2022 елның 18 февралендәге 7 номерлы карары;
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге башкарма комитетының «2023 елга Күтәмә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасын раслау турында» 2022 елның 27 декабрендәге 24 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Н.Г.Сабиров